СОВЕТ КАМАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 село Камаево, ул.Дифгата Сирая д.29А

423643 Камай авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел.(885549)3-55-33 ИНН 1627001164, КПП162701001 ОГРН 1021601118043

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 30 нчы июленнән № 165

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаларны башкаручыны алмаштыручы һәм муниципаль хезмәткәрләренең эш вазифаларына бәйле яки алар тарафыннан хезмәт вазифаларын башкарган өчен бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү тәртибе, сату (сатып алу) һәм кабул итү, аны сатудан кергән акча турындагы нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законның 2 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" 30.10.2018 ел, № 387-ФЗ Федераль закон нигезендә", Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2014 елның 6 февраленнән 65 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаларны башкаручыны алмаштыручы һәм муниципаль хезмәткәрләренең эш вазифаларына бәйле яки алар тарафыннан хезмәт вазифаларын башкарган өчен бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү тәртибе, сату (сатып алу) һәм кабул итү, аны сатудан кергән акча турындагы нигезләмәсе”дәге 2 нче пунктының 2 нче абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат - депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булган муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе әгъзасы, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән комиссиядә даими (штат) нигезендә эшләүче. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы Рәисе урынбасары, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы аудиторы вазыйфалары Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль вазыйфаларга кертелергә мөмкин”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" челтәрендә урнаштырырга .

Камай авыл җирлеге башлыгы: И.И.Әһлиева